**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 31 декабрь № 1043

г. Казань

2016 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында

Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлегендә катнашучылар арасындагы үзара хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бу карар белән расланган 2016 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумы нигезләмәләрен акцияләре милек хокукында Татарстан Республикасыныкы булган инвестиция эшчәнлеге субъектларына җиткерергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип санарга:

«2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1089 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1089 нчы карары белән расланган 2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 17 февраль, 98 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1089 нчы карары белән расланган 2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 3 март, 125 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1089 нчы карары белән расланган 2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 2 апрель, 210 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь,

1089 нчы карары белән расланган 2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 22 май, 365 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1089 нчы карары белән расланган 2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 20 июнь, 448 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1089 нчы карары белән расланган 2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 30 июнь, 477 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1089 нчы карары белән расланган 2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 5 сентябрь, 642 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1089 нчы карары белән расланган 2015 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 12 сентябрь, 673 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1043.docx

2016 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына 2 нче кушымта

**2016 елга минималь куллану бюджеты нигезендә исәпләнгән Татарстан Республикасына кертелә торган азык-төлек булмаган продукциясе һәм республикадан алып чыгыла торган финанс чаралары күләмнәрен бәяләү**

| Продукция исеме | Үлчәү берәмлеге | Республика халкының продукцияне куллану күләме, бер елга | Ихтыяҗда республикага алып керелгән продукция өлеше, процент | Ихтыяҗда республикада җитештерелгән продукция өлеше, процент | Республикадан алып чыгылган финанс чаралары зурлыгын бәяләү, бер елга млн. сум |
|---|---|---|---|---|---|
| Санитария и гигиена предметлары | мең данә | 372 011 | 43,0 | 57,0 | 8 612,6 |
| Дару чаралары | мең тартма | 731 590 | 86,1 | 13,9 | 22 124,4 |
| Урын-җир әйберләре | мең данә | 11 550 | 100,0 | 0,0 | 3 544,4 |
| Эчке кием трикотажы | мең данә | 26 985 | 99,1 | 0,9 | 4 468,3 |
| Өс киеме | мең данә | 22 340 | 97,2 | 2,8 | 26 897,0 |
| Баш киеме | мең данә | 2 872 | 98,7 | 1,3 | 3 294,5 |
| Аяк киеме | мең пар | 15 565 | 94,8 | 5,2 | 19 310,9 |
| Оек-оекбаш эшләнмәләре | мең пар | 32 768 | 85,8 | 14,2 | 2 179,2 |
| Өске кием трикотажы | мең данә | 12 991 | 99,3 | 0,7 | 5 073,2 |
| Көнкүреш электр товарлары | данә | 860 444 | 64,6 | 35,4 | 1 351,9 |
| Фарфор-фаянс савыт-саба | мең данә | 10 814 | 83,6 | 16,4 | 510,0 |
| Ашханә кирәк-яраклары (тутыкмас корычтан эшләнгән пычаклар, чәнечкеләр һәм кашыклар) | мең данә | 1 494 | 98,8 | 1,2 | 67,6 |
| Хуҗалык билгеләнешендәге товарлар | данә | 5 373 922 | 83,9 | 16,1 | 5 923,2 |
| Мәдәният-спорт билгеләнешендәге товарлар | мең данә | 157 533 | 68,9 | 31,1 | 5 193,4 |
| Металл савыт-саба | мең данә | 1 631 | 79,0 | 21,0 | 341,0 |
| Пыяла сортлы савыт-саба | мең данә | 1 823 | 99,0 | 1,0 | 18,0 |
| Агач товарлар | мең данә | 482 | 100,0 | 0,0 | 21,3 |
| Радио товарлар | мең данә | 209 | 100,0 | 0,0 | 528,3 |
| БАРЫСЫ | | | | | 109 459,1 |

___

2016 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына 1 нче кушымта

**2016 елга минималь куллану бюджеты нигезендә исәпләнгән Татарстан Республикасына кертелә торган азык-төлек продукциясе һәм республикадан алып чыгыла торган финанс чаралары күләмнәрен бәяләү**

| Продукция исеме | Халыкның куллану нормативы, тонна | | | Халыкның ихтыяҗын каплау өчен кирәкле республикага кертелә торган продукция күләме, бер елга тонна | Халыкның продукция куллану нормативы күләмендә республикага алып кертелгән продукция өлеше, процент | Халыкның продукциягә ихтыяҗын каплау өчен республикадан алып чыгылган финанс чаралары күләме, бер елга млн. сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | айга | елга | халык хуҗалыкларын-да үстерелә торган продуктларны исәпләмичә, елга | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Икмәк-күмәч эшләнмәләре* | 35 980 | 431 764 | 431 764 | | | |
| Бодай оны * | 4 819 | 57 826 | 57 826 | | | |
| Макарон эшләнмәләр | 1 767 | 21 203 | 21 203 | 18 374 | 87 | 1 337,6 |
| Дөге | 803 | 9 638 | 9 638 | 9 638 | 100 | 846,4 |
| Ярма | 3 437 | 41 249 | 41 249 | 24 359 | 59 | 949,9 |
| Бәрәңге* | 33 410 | 400 924 | | | | |
| Яшелчәләр | 51 850 | 622 203 | 382 150 | 302 550 | 49 | 10 439,2 |
| Җимешләр | 24 897 | 298 765 | 233 007 | 166 207 | 56 | 16 552,8 |
| Ит һәм ит продуктлары: | 20 078 | 240 940 | 187 389 | 31 019 | | 9 107,4 |
| сыер ите | 8 674 | 104 086 | 89 476 | 24 086 | 23 | 6 796,8 |
| дуңгыз ите* | 1 124 | 13 493 | 1 341 | | | |
| сарык ите | 964 | 11 565 | 58 | 1 819 | 15 | 609,8 |
| кош* | 7 068 | 84 811 | 63 796 | | | |
| казылык, ысланган ит | 2 249 | 26 985 | 26 985 | 5 114 | 19 | 1 700,8 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Сөт, әче сөт продуктлары | 44 975 | 539 705 | 453 944 | 197 739 | 37 | 9 054,5 |
| Сыер мае | 1 928 | 23 130 | 23 130 | 4 971 | 21 | 1 401,0 |
| Сыр* | 964 | 11 565 | 11 565 | | | |
| Балык продуктлары | 6 104 | 73 246 | 73 246 | 68 254 | 93 | 10 161,3 |
| Шикәр һәм татлы ашамлыклар | 12 047 | 144 564 | 144 564 | | | |
| татлы ашамлыклар* | 4 337 | 52 043 | 52 043 | | | |
| шикәр* | 7 710 | 92 521 | 92 521 | | | |
| Күкәй, данә* | 78 064 | 936 774 | 635 411 | | | |
| Үсемлек мае* | 2 891 | 34 695 | 34 695 | | | |
| Майонез* | 161 | 1 928 | 1 928 | | | |
| Башкалар: | | | | | | |
| чәй | 386 | 4 626 | 4 626 | 4 626 | 100 | 1 640,8 |
| Эри торган кофе | 514 | 6 168 | 6 168 | 6 168 | 100 | 6 559,7 |
| какао-порошок | 386 | 4 626 | 4 626 | 4 626 | 100 | 2 221,7 |
| йодлаштырылган тоз | 1 446 | 17 348 | 17 348 | 17 348 | 100 | 212,2 |
| БАРЫСЫ | | | | | | 70 484,4 |

* Республикада җитештерелә торган продукция халыкның ихтыяҗын каплый, шулай да республикада аннан читтә җитештерелә торган продукция дә сатыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 декабрь, 1043 нче карары белән расланды

**2016 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумы**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумы (алга таба – Меморандум) Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген үстерүнең төп өстенлекләрен билгели.

1.2. Меморандум Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең стратегик максатын тормышка ашыруга – киләчәк икътисады нигезләрен, белемнәр икътисадын, ягъни киләчәктә татарстан икътисадының тотрыклы динамик үсеше нигезендә халыкның тормыш сыйфатын дөньякүләм стандартлар дәрәҗәсенә күтәрүне тәэмин итәргә һәм нәтиҗәдә дөньяның әйдәп баручы илләре үсеше траекториясенә чыгарга мөмкинлек бирәчәк икътисадны формалаштыруга юнәлдерелгән.

1.3. Меморандум ел саен Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасы басылып чыкканнан соң эшләнә.

1.4. Инвестиция эшчәнлеге субъектлары тарафыннан инвестиция эшчәнлеге планнары эшләнгәндә һәм расланганда Меморандум нигез сыйфатында тәкъдим ителә.

1.5. Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеге белән идарә итү буенча дәүләт сәясәтен эшләү вазыйфаларын тормышка ашыручы башкарма хакимият органы, шулай ук Меморандум нигезләмәләрен тормышка ашыру өчен җаваплы үзәк булып Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тора (алга таба – Координатор).

1.6. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы инвестицияләр җәлеп итү, инвестицион проектларны озата бару һәм тормышка ашыру, дәүләт-шәхси партнерлык мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы булып тора.

1.7. Татарстан Республикасының Инвестицион советы Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү мәсьәләләре буенча коллегиаль киңәшү органы булып тора.

1.8. Меморандум нигезләмәләрен үтәүне мониторинглауны Координатор гамәлгә ашыра.

1.9. Меморандум тексты Татарстан Республикасының ачык мәгълүмат ресурсларына кертелә.

2. Инвестицион сәясәтнең өстенлекле юнәлешләре

2.1. 2016 елда Татарстан Республикасы инвестицион сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре булып түбәндәгеләр тора:

нефть, газ, химия һәм машина төзелеше комплексларында эре югары технологияле проектларны тормышка ашыру;

нигездә яңа технологияләр кулланучы конкурентлыкка сәләтле производстволарны формалаштыру һәм үстерү;

яңа үсеш нокталарын булдыру, беренче чиратта ИТ-секторда, фармацевтика, био- һәм нанотехнологияләр тармакларында;

инжиниринг үзәкләрен үстерү, шул исәптән биотехнологияләр, робототехника, прототиплаштыру һәм санлы коелма өлкәләрендә;

инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен кирәкле социаль, транспорт, энергетика һәм инженер инфраструктурасының алга китеп үсүе;

импортны алыштыра торган технологияләр һәм продуктлар булдыру;

хезмәт җитештерүчәнлеген һәм энергия нәтиҗәлелеген күтәрү;

эшмәкәрлекне үстерү;

муниципаль районнарда (шәһәр округларында) сәнәгать мәйданнарын үстерү;

дәүләт-шәхси партнерлык практикасын киңәйтү;

инвестицияләр җәлеп итү һәм республика җитештерүчеләре продукциясен яңа базарларга, шул исәптән республиканың чит илдәге һәм Россия Федерациясе субъектларындагы вәкиллекләре аша, чыгару тармагында Россия Федерациясе төбәкләре һәм чит ил партерлары белән хезмәттәшлекне үстерү;

инвестицион климатны яхшырту;

инвестиция процессын мәгълүмат һәм кадрлар белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

киләчәктә социаль-мәдәни тармакны үстерү юлы белән республикада яшәүче халыкның тормыш сыйфатын күтәрү һәм яшәү өчен уңай мохит булдыру;

Татарстан Республикасы территориясендә инвестицион сәясәтнең өстенлекле юнәлешләренә җавап бирә торган инвестицион проектларны тормышка ашыруга булышлык күрсәтү;

2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегияләре, Меморандумда билгеләнгән проектларны да кертеп;

Россия Федерациясенең гамәлдәге салым законнары кысаларында салым ташламалары, инвестицион салым кредитлары бирү юлы белән Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция эшчәнлеге гамәлгә ашыручы предприятиеләргә (оешмаларга) дәүләт ярдәме, шулай ук инвестицион проектларга булышлык күрсәтүнең бүтән рәвешләре;

Татарстан Республикасының махсус икътисадый зоналарын булдыру һәм үстерү;

Татарстан Республикасының аеруча катлаулы социаль-икътисадый хәлдәге моношәһәрләрен үстерү, шул исәптән алга китеп социаль-икътисадый үсеш алган территорияләр төзү һәм үстерү исәбенә;

«Иннокам» территориаль-аерымланган инновацион-җитештерү үзәген булдыру һәм үстерү.

2.2. Меморандумда билгеләнгән инвестицион сәясәт юнәлешләре, социаль-икътисадый үсешнең нәтиҗәләрен һәм яна өстенлекләрен исәпкә алып, шулай ук законнардагы үзгәрешләрне күздә тотып, тәгаенләштерелергә мөмкин.

## 3. Инвестицион эшчәнлек субъектлары

Инвесторлар, заказчылар, подрядчылар, инвестиция эшчәнлеге объектларыннан файдаланучылар һәм инвестиция эшчәнлегенең башка катнашучылары сыйфатында чыккан, шул исәптән технополис территориясендә инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашырган физик һәм юридик затлар, шул исәптән чит илнеке, шулай ук дәүләтләр һәм халыкара оешмалар инвестиция эшчәнлеге субъектлары була ала.

## 4. Инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара бәйләнешләре

Инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара багланышлары тәртибе гамәлдәге законнар кысаларында билгеләнә һәм Россия Федерациясе халыкара шартнамәләре, федераль законнар һәм бүтән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә инвестиция эшчәнлеге субъектлары эшли торган регламентлар белән билгеләнә.

## 5. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары бурычлары

2016 елга Меморандум белән билгеләнә торган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының төп бурычлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан аларның компетенциясе кысаларында Россия Федерациясе төбәкләренең инвестицион климаты торышының милли рейтингы нәтиҗәлелеге күрсәткечләре буенча Татарстан Республикасының урынын күтәрүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан аларның компетенциясе кысаларында республикада инвестицион климатны яхшыртуга юнәлдерелгән «Яңа проектларны алга җибәрү буенча стратегик башлангычлар агентлыгы» автоном коммерциягә карамаган оешманың милли эшмәкәрлек башлангычының «юл карталары»н кертүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасында уңай инвестицион климатны тәэмин итү буенча башкарма хакимият органнары эшчәнлеге стандартын һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарында (шәһәр округларында) уңай инвестицион климатны тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеге стандартын тормышка ашыру кысаларында төзелгән механизмнар һәм коралларның нәтиҗәлелеген күтәрүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасы районнары (шәһәр округлары) арасындагы килешү белән билгеләнгән Татарстан Республикасы районнары (шәһәр округлары) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләрен үтәү.

6. 2016 елда өстенлекле инвестицион проектлар

6.1. 2016 елда тормышка ашыру өчен өстенлекле инвестицион проектларга түбәндәгеләр кертелә.

Авыл хуҗалыгы:

«Татарстан Республикасы Азнакай районының Актүбә поселогында мөгезле эре терлекнең савым көтүе өчен 4 000 башка исәпләнгән терлекчелек комплексы төзелеше» («Союз-Агро» ҖЧҖ, Азнакай муниципаль районы);

«1 200 баш сыерга исәпләнгән терлекчелек комплексы төзелеше» («Апас» агрофирмасы» ҖЧҖ, Апас муниципаль районы);

«Агромир-Казан» авыл хуҗалыгы продукциясен күпләп сату, саклау һәм эшкәртү логистика үзәге төзелеше (беренче чираты)» («Милли Продукт Корпорациясе» АҖ, Питрәч муниципаль районы);

«5,3 гектар мәйданлы теплица комплексы төзелеше» («Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ, Зеленодольск муниципаль районы);

«Заманча инновацион биотехнологияләр кертү нигезендә «Чулман» кошчылык продукциясен җитештерү һәм комплекслы эшкәртү буенча технополис төзү» («Чаллы элеваторы» ААҖ, Тукай муниципаль районы);

«Татарстан Республикасында югары сыйфатлы сыер ите җитештерүне оештыру» («Русский Мрамор» агросәнәгать комплексы» ЯАҖ, Балык Бистәсе муниципаль районы);

«Теплицаларда гөмбәләр һәм яшелчәләр үстерү буенча производство төзү» («Сверез» ҖЧҖ, Чаллы шәһәре).

Чи нефть чыгару:

«Әшәлче югары үзле нефтьләр чыганагын эшкәртү (СВН-1600)» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Әлмәт муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы);

«Татарстан Республикасында яңа җитештерү куәтләрен булдыру исәбенә «Татнефтеотдача» АҖ нефть чыгару күләмнәрен арттыру» («Татнефтеотдача» АҖ, Нурлат муниципаль районы, Сарман муниципаль районы).

Азык-төлек продуктлары җитештерү:

«Ак Барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖ төзү, төзекләндерү һәм яңарту: 2 этап» («Ак Барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖ, Питрәч муниципаль районы);

«Сәгатенә 10 500 баш җитештерү белән кош чалу предприятиесе» («Чаллы-Бройлер» ҖЧҖ, Чаллы шәһәре);

«144 тонна/тәүлек җитештерү белән кош эшкәртү предприятиесе» («Чаллы-Бройлер» ҖЧҖ, Чаллы шәһәре);

«Казан МЭЗ» ААҖ май сәнәгате предприятиесен яңарту» («Нәфис Косметикс» ГАҖ, Казан шәһәре);

«Шоколадлы татлы ашамлыклар җитештерү буенча кондитер фабрикасы төзелеше» («Күмәч-кондитер комбинаты» ААҖ, Казан шәһәре);

«Булгарпиво» ААҖ алкогольсез пиво продукциясен җитештерүне яңарту һәм киңәйтү» («Булгарпиво» ААҖ, Чаллы шәһәре);

«Татарстан Республикасында «Камский» агросәнәгать комплексы» ҖЧҖдә итне беренче эшкәртү һәм казылык эшләнмәләре җитештерү предприятиесен төзү, төзекләндерү» («Камский» агросәнәгать комплексы» ҖЧҖ, Тукай муниципаль районы).

Целлюлоза-кәгазь җитештерү, нәшрият һәм полиграфия эшчәнлеге:

«Татарстан Республикасында кәрәзле картон паллетлар (астартмалар) җитештерүен булдыру» («Габбропро» ҖЧҖ, Казан шәһәре).

Нефть продуктларын җитештерү:

«Түбән Кама шәһәрендә нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексының гидрокрекинг һәм нигез майлар производствосы» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «ТАНЕКО» АҖ, Түбән Кама муниципаль районы);

«Түбән Кама шәһәрендә «Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексының» тирән эшкәртү комплексы төзелеше (1.3 – 1.5 этап)» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «ТАНЕКО» АҖ, Түбән Кама муниципаль районы);

«ТАИФ-НК» ААҖ нефть эшкәртү заводының авыр калдыкларын тирән эшкәртү буенча комплексы төзелеше («ТАИФ-НК» ААҖ, Түбән Кама муниципаль районы.

Химия җитештерүе:

«Яңа олефин комплексы төзелеше – I этап (ЭП-600)» («Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ, Түбән Кама муниципаль районы);

«Изопрен җитештерү куәтен үстерү (шул исәптән изобутилен һәм формальдегид җитештерүне оештыру)» («Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ, Түбән Кама муниципаль районы);

«Елына 100 мең тонна куәтле дивинил-стироль синтетик каучук җитештерүе төзелеше» («Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ, Түбән Кама муниципаль районы);

«Турбулентка каршы утырма һәм углеводород катнашмалары өчен файдаланыла торган коррозиянең ингибаторы үзенчәлекләренә ия комплекслы тәэсир итә торган реагентны нефть химиясе җитештерүе» («Миррико Казан» ҖЧҖ, Әлмәт муниципаль районы);

«Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре Промзонасы территориясендә аммиак, метанол һәм карбамид җитештерү буенча комплекс төзелеше» («Аммоний» АҖ, Менделеевск муниципаль районы);

«Метилхлорсиланнарны аерым сәнәгать җитештерүе төзелеше» («КЗСК-Силикон» ААҖ, Казан ш.);

«Maxsil силикон төзелеш герметикларын җитештерүне оештыру» («Казан синтетик каучук заводы» ААҖ, Казан шәһәре);

«Микронлашкан силикагельләр җитештерүне оештыру» («Л.Я.Карпов исемендәге химия заводы» АҖ, Менделеевск шәһәре);

«Дару майлар җитештерү буенча цех төзү» («Татхимфармпрепараты» ААҖ, Казан шәһәре);

«Синтетик юу чаралары житештерү буенча яңа завод төзелеше» («Нәфис Косметикс» ГАЖ, Казан шәһәре);

«Түбән Кама шин» ГАЖдә тыгызландырылган һава җитештерүне төзекләндерү» («Түбән Кама шин» ГАЖ, Түбән Кама муниципаль районы);

«Түбән Кама шин» ГАЖдә әзерлек җитештерүен төзекләндерү» («Түбән Кама шин» ГАЖ, Түбән Кама муниципаль районы);

«Тасма» ФҖП» ҖЧҖ мәйданнарында күп катламлы барьер пленка җитештерүне оештыру» («Тасма» фәнни-җитештерү предприятиесе» ҖЧҖ, Казан шәһәре).

Резина һәм пластмасса әйберләр җитештерү:

«Татарстан Республикасында AD*STAR® коробка төрдәге тукылган полипропилен капчыклар җитештерүне булдыру» («Казан заманча төрү материаллары заводы» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

«Пневматик тиз аерыла торган тоташтыргычлар» («Тиссан» ҖЧҖ, Чаллы шәһәре, Төзелеш индустриясе-промзона базасы, «Мастер» Кама индустриаль паркы);

«Диаметры 800 мм.га кадәр булган полиэтилен басымлы торбалар һәм фасонлы эшләнмәләр җитештерүне үзләштерү» («Газпласт» ҖЧҖ, Казан шәһәре).

Бүтән металл булмаган минераль продуктлар җитештерү:

«Татарстан Республикасының Тәтеш районында кирпеч заводы төзелеше» («КерамРесурс» ҖЧҖ, Тәтеш муниципаль районы);

«Татарстан Республикасының Апас районында елына 60 млн. данә шартлы кирпеч чыгару куәте белән Каратун кирпеч заводы төзелеше» («Стройсервис» ҖЧҖ, Апас муниципаль районы);

«Керамощебень» («САНЭКО» фәнни-житештерү фирмасы» ҖЧҖ, Саба муниципаль районы);

«Эшкәртелгән табигый диатомит нигезендә яңа буын югары нәтиҗәле төзелеш материалларын җитештерүне оештыру» («Ресурс төзелеш технологияләре» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

«Кама Тамагында төзелеш гипсы заводын төзү» («Кама Тамагы төзелеш гипсы заводы», Кама Тамагы муниципаль районы);

«Импортны алыштыручы ассортиментлы программа белән сугылган продукция (фасад кирпече, кирпечкә охшаган каплый торган плитка, тротуар плиткасы, түшәлмә таш һәм кирпеч, дивар һәм идән плиткасы) җитештерү буенча яңа кирпеч заводы төзелеше» («Кирпеч заводы» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

«Татарстан Республикасы шикәр заводларының күптонналы калдыкларын (дефекат һәм чөгендер түбен) файдаланып, гипстан әйберләр, коры төзелеш кушылмалары җитештерү» («Казан Гипронииавиапромы» АҖ, Буа шәһәре).

Металлургия житештерүе һәм әзер металл әйберләр җитештерү:

«Металл коюю производствосын яңарту» («Магнолия» Чаллы металл коюмеханика заводы» ҖЧҖ, Чаллы шәһәре).

Машиналар һәм җиһазлар җитештерү:

«Пентаннар һәм изобутан хладагенты нигезендә углеводородлы күбекләндерүне кертеп, энергия нәтиҗәле, экологик куркынычсыз технологияләр

нигезендә көндәшлеккә сәләтле POZIS суыту техникасын җитештерүне үзләштерү» («Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» АҖ, Зеленодольск шәһәре);

«Импортны алыштыру программасы кысаларында медицина суыту техникасын инновацион җитештерүне булдыру» («Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» АҖ, Зеленодольск шәһәре).

Электр җиһазлары, электрон һәм оптик җиһазлар җитештерү:

«Хирургия өчен энә очлы синтетик әкренләп таралып бетә торган җепләр җитештерүне булдыру» («МЕДТЕХНИКА» җитештерү-сәүдә берләшмәсе» ЖЧЖ, Казан шәһәре);

«Оптоэлектроника өчен синтетик сапфир җитештерү, 2 нче этап» («Кама Кристалл Технолоджи» ЖЧЖ, Чаллы шәһәре);

«Кабель-үткәрү продукциясен җитештерүне үстерү» («ПРЕТТЛЬ-НК» ЖЧЖ, Түбән Кама шәһәре);

«Сыгылмалы алюминий үткәргеч җитештерү» («ПРЕТТЛЬ-НК» ЖЧЖ, Түбән Кама шәһәре);

«Тимер юл тармагы предприятиеләре өчен кабель-үткәрү һәм электр техникасы продукциясен җитештерүне үстерү» («ПРЕТТЛЬ-НК» ЖЧЖ, Түбән Кама шәһәре).

Транспорт чараларын һәм җиһазларын җитештерү:

«КамАЗ» автомобильләренең модель рәтен үстреү («КАМАЗ» ГАҖ, Чаллы шәһәре);

«КАМАЗ» ГАҖ өчен тормозның коелма кысасын җитештерүне оештыру («ТР ИВФ» ККО, Актаныш муниципаль районы);

«Туполев» ГАҖ филиалы – С.П.Горбунов исемендәге КАЗ корпусларын һәм биналарын ягып җылыту (газлаштыру) системасын яңарту («Туполев» ГАҖ филиалы – С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы, Казан шәһәре);

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең «Казан вертолет заводы» ГАҖнең «Юдино» Казан аэродром базасын төзекләндерү («Казан вертолет заводы» ГАҖ, Казан шәһәре);

«Казан вертолет заводы» ГАҖнең сынаулар базасын төзекләндерү» («Казан вертолет заводы» ГАҖ, Казан шәһәре);

«КВЗ» ГАҖнең калаклар җитештерүен төзекләндерү һәм техник яңадан коралландыру» («Казан вертолет заводы» ГАҖ, Казан шәһәре);

«КВЗ» ГАҖ җитештерүен төзекләндерү» («Казан вертолет заводы» ГАҖ, Казан шәһәре).

Газ һәм су электр энергиясен җитештерү һәм бүлү:

«Щелоков – Бегишево 220 кВ электр үткәрү һава линиясе (ҺЛ) төзелеше» («Сетевая компания» ААҖ, Алабуга муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы);

«Бегишево 220 кВ ярдәмче станциясе (ЯС) төзелеше» («Сетевая компания» ААҖ, Түбән Кама муниципаль районы);

«Щелоков – Үзәк 220 кВ электр үткәрү һава линиясе (ҺЛ) төзелеше» («Сетевая компания» ААҖ, Менделеевск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы);

«Бөгелмә 500 кВ ярдәмче станциясе (ЯС) төзелеше» («Сетевая компания» ААЖ, Бөгелмә муниципаль районы);

«Киндери 500 кВ ярдәмче станциясе (ЯС) төзелеше» («Сетевая компания» ААЖ, Казан ш.);

«ГТҖ базасында Казан ТЭЦ-3 яңарту» («ТГК-16» ААЖ, Казан шәһәре);

«5 нче газ-мазут станциясенең казанлы агрегаты. II дәрәҗә конвектив пар җылыткычны алыштырып, казанны техник яңадан коралландыру» («Генерацияләүче компания» ААЖ, Зәй муниципаль районы);

«Зәй ГРЭСта һәркайсы 500 МВт куәтле ике ГТҖ төзелеше» («Генерацияләүче компания» ААЖ, Зәй шәһәре);

«Гидрогенератор СВ 1470/149-104 У4 (№11). Статорны һәм роторның кысасын яңарту» («Генерацияләүче компания» ААЖ, Чаллы шәһәре);

«Чаллыны кайнар су белән тәэмин итүдә (КСТИ) тулыландырып торучы суның кимүе белән бәйле Чаллы ТЭЦ җылылык челтәрен тулыландыру схемасын яңарту» («Генерацияләүче компания» ААЖ, Чаллы шәһәре);

«Гомуми билгеләнгән 230 МВт электр куәтле Казан ТЭЦ-1дә ике энергия блогы төзелеше» («Генерацияләүче компания» ААЖ, Казан шәһәре);

«Зәй ДРЭС станциясенең конденсацияләү блокларын реновацияләү» («Генерацияләүче компания» ААЖ, Зәй шәһәре);

«Табигый газны җитештерү, саклау һәм бирү буенча комплекс төзелеше» («Семирамида» агросәнәгать комплексы» ҖЧҖ, Теләче муниципаль районы);

«Урыссу ДРЭСны төзекләндерү. 66 МВт пар-газ җайланмасын (ПГҖ) төзү» («Урыссу ДРЭС ТГК» ЯАЖ, Ютазы муниципаль районы).

Транспорт һәм элемтә:

«Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәген төзү (Татарстан Республикасы)» (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, «Ространсмодернизация» федераль казна учреждениесе, Зеленодольск муниципаль районы);

«Татарстан Республикасында «Казан – Оренбург» федераль автомобиль юлының яңа маршрутын үстерү өчен «Шәле (М-7) – Баулы (М-5)» түләүле автомагистрале төзелеше» (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Алексеевск, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Лаеш, Лениногорск, Яңа Чишмә, Питрәч, Балык Бистәсе, Чирмешән, Чистай муниципаль районнары);

«Мамадыш шәһәре районында 970 км «Волга» М-7 юлыннан алып Кама елгасы аша күпер белән, Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узып, км 1066 «Волга» М-7 юлына чыга торган автомобиль юлы төзелеше» (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Мамадыш, Түбән Кама, Тукай муниципаль районнары).

Бүтән проектлар:

«Чаллы шәһәрендә канализация чистарту корылмалары утырмаларын киптерү һәм пиролиз эшкәртү комплексы төзелеше» («ИнтерБизнесГруппИнжиниринг» ҖЧҖ, Мәскәү шәһәре);

«ИнноКам территориаль аерымланган инновацион җитештерү үзәге төзелеше» (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Кама инновацион территориаль

җитештерү кластеры коммерциягә карамаган партнерлык ассоциациясе», Чаллы шәһәре, Алабуга, Зәй, Менделеевск, Түбән Кама һәм Тукай муниципаль районнары);

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» («Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ, Алабуга муниципаль районы);

«Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территориясендә урнашкан «Иннополис» махсус икътисадый зонасы («Иннополис» махсус икътисадый зонасы АҖ, Югары Ослан муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы);

«Татарстан Республикасының Кама аръягы-Кама буе зонасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү һәм аларны эшкәртү буенча инвестицион проект» («Идел буе экологик компаниясе» ҖЧҖ, Чаллы ш., Әгерҗе, Актаныш, Алабуга, Зәй, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Сарман, Тукай муниципаль районнары);

«Химград» Технополисы нигезендә индустриаль парк» (1 нче чират, 2 нче этап)» («Тасма-Инвест-Торг» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

«Тукыма эшләнмәләрне сәнәгать эшкәртүе һәм арендалау буенча җитештерү-логистика комплексы» («Коттон Вэй» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

«Татарстан Республикасы агросәнәгать паркы» («Казан» агросәнәгать паркы» ААҖ, Казан шәһәре);

«Сортларга бүлү-руданы баектыру комплексы белән руда булмаган төзелеш материалларын чыгару буенча үзе йөрми торган җир снарядын проектлау һәм төзү» («Активист» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

«Яна Тура» технополисы сәнәгать – логистика комплексы төзелеше» («Яна Тура – Агро» ҖЧҖ, Зеленодольск районы, Октябрь авыл җирлеге);

«Сертификация үзәге» (Чаллы шәһәре һәм Кама аръягы төбәге машина төзүчеләре ассоциациясе, Чаллы шәһәре);

«Машина төзелешендә прототиплаштыру һәм сәнәгать дизайны инжиниринг үзәге» (Чаллы шәһәре һәм Кама аръягы төбәге машина төзүчеләре ассоциациясе, Чаллы шәһәре);

«Пять ветров» Татарстан Республикасының идел-Кама бассейнында эчке һәм читтән керә торган туристлыкны үстерү» (Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты);

«Татнефть-Нефтехим» ИК» ҖЧҖ нефть химиясе һәм нефть эшкәртү тармагы предприятиеләре һәм «КНИТУ» ЮһБ ФДББУ һәм «Түбән Кама индустрия техникумы» ДАҺБУ мәгариф учреждениеләренең челтәр багланышлары юлы белән белем бирү, фән һәм гамәлиятнең бергәләштерүен тәэмин итү» («Татнефть – Нефть химиясе» идарә компаниясе», Түбән Кама шәһәре);

«Cryptogramm» (Криптооперацияләрне читтән торып үткәрү мөмкинлеге белән мәгълүматны саклау һәм алмашу өчен болытлы сервис һәм инфраструктур нәтиҗә) («Универсаль ИТ системалар» ҖЧҖ, «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә технопарк» ДАУ, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Казан шәһәре);

«iGuard» (Саклана торган предприятиенең бизнес-процессларын автоматлаштыру)» («Юнит Менеджмент» ҖЧҖ, «ИТ-парк» югары технологияләр

өлкәсендә технопарк» ДАУ, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Казан шәһәре);

«Smart Escrow» (Килешүләрдә йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү өчен сервис) («Эскроу консалтинг» ҖЧҖ, «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә технопарк» ДАУ, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Казан шәһәре);

«Диабетограф» программа комплексын булдыру» («Фреомед» ҖЧҖ, «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә технопарк» ДАУ, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Казан шәһәре);

«РОСКОНТЕНТ – идарә ителә торган WiFi-Челтәрләр» (аэропортлар, кафе, ресторан, сәүдә үзәкләре, кинотеатрлар кебек төрле җәмәгать урыннарында урнашкан бушлай WiFi тоташу нокталарын берләштерә) («АйТи-Трейдинг» ҖЧҖ, «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә технопарк» ДАУ, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Казан шәһәре);

«Массакүләм мәгълүмат чараларында реклама, PR, маркетинг чараларын үткәрүнең нәтиҗәлелегенә аудит һәм аналитика хезмәтләрен күрсәтү өчен программа белән тәэмин ителешне эшләү» («Чиста мәгълүмат» ҖЧҖ, «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә технопарк» ДАУ, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Казан шәһәре);

«ICL Cloud инновацион болытлы платформа һәм мәгълүматларны саклауның модульле масштаблаштырыла торган программа-аппарат комплексын булдыру» («ДжиДиСи Сервисез» ҖЧҖ, «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә технопарк» ДАУ, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Казан шәһәре);

«Агроинновацияләр. Хайваннарның бердәм автоматлаштырылган реестры» («Агроинновацияләр» ҖЧҖ, «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендә технопарк» ДАУ, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Казан шәһәре);

«Алабуга» сәнәгать-житештерү тибындагы, «Иннополис» техника-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зоналар территорияләрендә тормышка ашырыла һәм тормышка ашырырга планлаштырыла торган инвестицион проектлар;

югарыда атап кителмәгән, Татарстан Республикасының монопрофильле торак пунктларны үстерүнең комплекслы инвестицион планнарына һәм «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2015 – 2018 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү» ярдәмче программасына кергән инвестицион проектлар;

югарыда атап кителмәгән, технопарклар (индустриаль парклар), инновацион-технологик үзәкләр, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәте яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә төзелгәннәре территорияләрендә тормышка ашырыла һәм тормышка ашырырга планлаштырыла торган инвестицион проектлар;

Татарстан Республикасының алга китеп үскән территорияләрендә тормышка ашырыла һәм тормышка ашырырга планлаштырыла торган инвестицион проектлар.

6.2. Салым ташламалары рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү белән тормышка ашыруга хупланган өстенлекле инвестицион проектлар.

Авыл хуҗалыгы:

«Бөгелмә комбиазык заводын төзекләндерү» («Репродукт» ҖЧҖ, Бөгелмә муниципаль районы).

Азык-төлек продуктлары җитештерү:

«Рапс орлыгы маен тирәнтен эшкәртү буенча җитештерү комплексы төзелеше» («НӘФИС-БИОПРОДУКТ» ААҖ, Лаеш муниципаль районы);

«Кош үстерү һәм ит продуктлары җитештерү буенча комплексны төзекләндерү һәм янарту» («Залесный» агрофирмасы» ҖЧҖ, Зеленодольск муниципаль районы);

«Ак Барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖ төзү, төзекләндерү һәм яңарту: 1 этап» («Ак Барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖ, Питрәч муниципаль районы).

Целлюлоза-кәгазь җитештерү:

«Санитария-гигиена билгеләнешендәге кәгазьне һәм аннан эшләнмәләр җитештерүне оештыру» («ПАЛП Инвест» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

«Гофрокатыргының яссы катлары өчен катыргы һәм гофрлаштыру өчен кәгазь җитештерүнең куәтен арттыру буенча «С.П.Титов исемендәге ЧККК ХП» ЯАҖ катыргы фабрикасын яңарту» («С.П.Титов исемендәге Чаллы катыргы-кәгазь комбинаты халык предприятиесе, Чаллы шәһәре).

Химия җитештерүе:

«Бутил һәм галобутил каучуклар җитештерү куәтен 200 000 тн/ел кадәр үстерү – 1 этап: Галобутил каучуклар җитештерү куәтен 100 000 тн/ел кадәр арттыру» («Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ Түбән Кама муниципаль районы);

«Елга 50 мең тоннага кадәр куәт белән полистирол җитештерү (4 нче линия)» («Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ Түбән Кама муниципаль районы);

«Елга 40 мең тоннага кадәр куәт белән стретч-пленка җитештерү (4 нче һәм 5 нче линияләр)» («Кама Аланы индустрия паркы» идарә компаниясе» ҖЧҖ, Түбән Кама муниципаль районы);

«Сыгымалы төрү материаллары һәм полимер пленка материаллар җитештерү буенча завод төзелеше» («ДАНАФЛЕКС-НАНО» ҖЧҖ, Казан шәһәре).

Резина һәм пластмасс эшләнмәләр җитештерү:

«Ай-Пласт» ҖЧҖнең каты көнкүреш калдыклары полимер контейнерлары җитештерүне оештыру» («Ай-Пласт» ҖЧҖ, Түбән Кама муниципаль районы).

Металл булмаган бүтән минерал продуктлар җитештерү:

«Фоника Гипс» ҖЧҖнең гипс ташы чыгару һәм эшкәртү һәм гипстан төзелеш материаллары җитештерү буенча җитештерү комплексы» (AKSOLIT сәүдә маркасы)» («Фоника Гипс» ҖЧҖ, Кама Тамагы муниципаль районы);

«Татарстан Республикасы Биектау районында 150 млн. данә шартлы кирпеч куәтле керамик кирпеч җитештерүне оештыру» («Винербергер Куркачи» ҖЧҖ, Биектау муниципаль районы);

«Казан ДСК» ҖЧҖ йорт төзү комбинаты җитештерүен яңарту» («Казан ДСК» ҖЧҖ, Казан шәһәре).

Металлургия җитештерүе һәм әзер металл эшләнмәләр җитештерү:

«Кайнар цинклау цехы төзелеше» («Ак Барс Металл» ҖЧҖ, Чаллы шәһәре).

Машиналар һәм җиһазлар җитештерү:

«АЛНАС» ААҖ җитештерүен техник яңадан коралландыру» («АЛНАС» ААҖ, Әлмәт муниципаль районы);

«Россиядә Хайер суыткычларын җитештерү проекты» («Хайер Электрикал Эпплаенсис РУС» ҖЧҖ, Чаллы шәһәре).

Электр җиһазлары, электрон һәм оптик җиһазлар җитештерү:

«Оптоэлектроника өчен синтетик сапфир җитештерү» («Кама Кристалл Технолоджи» ҖЧҖ, Чаллы шәһәре).

Транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерү:

«CUMMINS дизель йөрткечләрен һәм автокомпонентларын җитештерү һәм төрле базарларга алып чыгу буенча уртак предприятие төзү» («КАММИНЗ КАМА» ЯАҖ, Чаллы шәһәре);

«Чит ил брендлары автомобильләрен җитештерү һәм Россия базарына алып чыгу» («Форд Соллерс Холдинг» ҖЧҖ, Чаллы ш);

«Авыл хуҗалыгы һәм төзелеш техникасын җитештерү буенча уртак предприятие булдыру» («СиЭнЭйч Индастриал (Россия) Индастриал Оперейшнз» ҖЧҖ, Чаллы шәһәре);

«Самолетлар өчен полимер композит материаллардан (ПКМ) канатны механизацияләү агрегатларын җитештерү буенча завод» («КАПО-Композит» ЯАҖ, Казан шәһәре);

«Чаллы шәһәрендә яңа җитештерү мәйданнарында локальләштерүнең тирән дәрәҗәсе белән ZF FRIEDRICHSHAFEN AG фирмасы лицензиясе буенча тапшыру тартмаларын яңа җитештерүне оештыру» («ЦФ КАМА» ҖЧҖ, Чаллы шәһәре).

Газ һәм су электр энергиясен җитештерү һәм бүлү

«Татнефть» ГАҖ объектларында Capstone микротурбина җайланмалары ярдәмендә электр энергиясен эшләп чыгару өчен уңай нефть газын утильләштерү» (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Әлмәт муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Зәй муниципаль районы);

«Татойлгаз» ААҖ объектында Capstone микротурбина җайланмалары ярдәмендә электр энергиясен эшләп чыгару өчен уңай нефть газын утильләштерү» («Татойлгаз» ААҖ, Лениногорск муниципаль районы);

«Татех» ЯАҖ Онбий нефть чыганагының ДНС-30да Capstone микротурбина җайланмалары ярдәмендә электр энергиясен эшләп чыгару өчен уңай нефть газын утильләштерү» («Татех» ЯАҖ, Зәй муниципаль районы);

«Майский энергоүзәге» («Майский энергоүзәге» ЯАҖ, Зеленодольск муниципаль районы).

Транспорт һәм элемтә:

«2013 елда XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадага транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итү өчен тимер юл инфраструктурасын үстерү (аэропортка кадәр тимер юл линиясе төзелешен исәпкә алмыйча)» («Россия тимер юллары» ААҖ, Казан шәһәре, Әгерҗе муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы);

Казан тимер юлы станциясеннән алып «Казан» халыкара аэропортына кадәр интермодаль ташуларны оештыру» («Россия тимер юллары» ААҖ, Казан шәһәре, Лаеш муниципаль районы).

Бүтән проектлар:

«Яңа Тура» технополисын төзү» («Яңа Тура» технополисы» идарә компаниясе» ҖЧҖ, Зеленодольск муниципаль районы);

«Химград» технополисы территориясендә индустриаль парк» («Тасма-Инвест-Торг» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

«Бөртекле һәм майлы культуралар саклау өчен элеватор төзелеше» («Агротехнологияләр» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы);

«Иннополис» территориаль аерымланган инновация үзәге төзелеше проектын тормышка ашыру кысаларында университет комплексы төзелеше» («Иннополис» ААҖ, Югары Ослан муниципаль районы).

7. 2016 елда Татарстан Республикасында
өстенлекле дәүләт программалары исемлеге

2016 елда финанслау өчен тәкъдим ителгән дәүләт программалары:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланган «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән расланган «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 30 июль, 531 нче карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 август, 545 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының дәүләт финанслары белән идарә итү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2013 ел, 13 сентябрь, 656 нчы карары белән расланган «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014 - 2016 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 785 нче карары белән расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014 - 2016 еллар)» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карары белән расланган «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 4 декабрь, 954 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 декабрь, 997 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1000 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нче карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән расланган «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында физик культура, спорт, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен тормышка ашыру нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 7 февраль, 73 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында физик культура, спорт, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен тормышка ашыру нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау

турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 30 апрель, 289 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2015 ел, 21 июль, 522 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының химик һәм биологик куркынычсызлык системасы» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 24 сентябрь, 672 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасының химик һәм биологик куркынычсызлык системасы» дәүләт программасы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015-2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 3 декабрь, 943 нче карары белән расланган «2015-2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы.

## 8. Республиканың товарлар базары потенциалы

Республика товар җитештерүчеләре тарафыннан үзләштерелмәгән республиканың азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар базары потенциалы Россия һәм чит ил предприятиеләреннән товарлар сатып алу күләме белән билгеләнә.

2016 елга төп куллану товарлары буенча базарның сыйдырышлылыгы фаразы әлеге Меморандумга 1 нче һәм 2 нче кушымталарда китерелә.

---